ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЮТАЗЫ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
ИСКЕ КАРАЗИРЕК АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ

# КАРАРЫ

№ 32 Иске Каразирек ав. 2023 елның 17 ноябре

Татарстан Республикасы Ютазы
муниципаль районы Иске Каразирек авыл җирлеге
Советының карарлары үз көчен
югалтуларын тану турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында» 2007 елның 02 мартындагы 25-ФЗ номерлы Федераль закон, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 28.07.2004 № 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, Муниципаль хезмәт турында Татарстан Республикасы Кодексы, Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының «Иске Каразирек авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставы, Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгының 13.11.2023 елның 13 ноябрендәге 16094419202300023 номерлы хокукый экспертиза бәяләмәсе нигезендә, норматив хокукый актларны Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасы законнарына туры китерү максатларында, Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының Иске Каразирек авыл җирлеге Советы карар кабул итә:

1. Көчен югалткан дип танырга:

- Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының «Иске Каразирек авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә муниципаль хезмәткәрләр тарафыннан коммерциячел булмаган оешмалар белән идарә итүдә (сәяси партиядән тыш) бердәнбер башкарма орган сыйфатында түләүсез катнашуга яисә аларның коллегиаль идарә органнары составына керүгә яллаучы (эш бирүче) вәкиленең рөхсәтен алу тәртибе турындагы нигезләмәне раслау хакында 2023 елның 18 сентябрендәге 17 номерлы карары;

- Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының « Иске Каразирек авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә муниципаль хезмәткәрләр тарафыннан бердәм башкарма орган буларак, яллаучы (эш бирүче) вәкиленең (сәяси партиядән тыш) бушлай нигездә коммерцияле булмаган оешмалар белән идарә итүдә катнашу яисә аларның коллегиаль идарә органнары составына керү өчен рөхсәт алу тәртибе турындагы Нигезләмәне раслау хакында" 2017 елның 18 августындагы 9 номерлы карары.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының « Иске Каразирек авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясендә махсус мәгълүмат стендларында игълан итәргә, Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат порталында http://pravo.tatarstan.ru/ адресы буенча бастырып чыгарырга һәм Татарстан Республикасының Ютазы муниципаль районы сайтында Татарстан Республикасының Бердәм Дәүләт хакимияте органнары һәм җирле үзидарә органнарының «Рәсми Татарстан» бердәм Порталы составында «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасының http://javo.tatarstan.ru/ адресы буенча урнаштырырга.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыккан вакыттан үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Иске Каразирек авыл җирлеге башлыгы
вазифаларын башкаручы Э.М.Минниярова